ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» 2022 елның 29 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 34 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендәге 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2) Татарстан Республикасының дәүләт милке булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү турында йә балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын үзгәртеп төзү яисә бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү тәртибен, мондый карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясен төзү һәм әлеге комиссия тарафыннан бәяләмәләр әзерләү тәртибен билгеләү;»;

2) 4 статьяда «һәм тәмәке әйберләре» сүзләрен «, тәмәке әйберләре яисә никотинлы продукция» сүзләренә алмаштырырга, «традицион булмаган сексуаль мөнәсәбәтләрне пропагандалый торган мәгълүматтан» сүзләрен «традицион булмаган сексуаль мөнәсәбәтләрне һәм (яисә) өстенлекләрне пропагандалый йә күрсәтә торган мәгълүматтан, педофилияне пропагандалый торган мәгълүматтан, балаларда җенесне алыштыру теләге уятырга сәләтле мәгълүматтан» сүзләренә алмаштырырга;

2) 5 статьяда:
а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт милке яисә муниципаль милек

булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү турында йә балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмасын яисә муниципаль оешманы үзгәртеп төзү яисә бетерү турында карар кабул итү балаларның тормыш эшчәнлеген, аларга белем бирүне, аларны үстерүне, аларның ялын һәм аларны савыктыруны, аларга медицина ярдәме күрсәтүне, балалардагы авыруларны профилактикалауны, аларны социаль яклауны һәм аларга социаль хезмәт күрсәтүне тәэмин итү өчен мондый карарның нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясенең уңай бәяләмәсе нигезендә рөхсәт ителә.

Татарстан Республикасы дәүләт милке яисә муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектының билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү Федераль законның 13 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацы нигезендә билгеләнгән очракларда рөхсәт ителә.

Балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын, муниципаль оешмаларны үзгәртеп төзү граждан законнарында билгеләнгән очракларда Татарстан Республикасы дәүләт милке яисә муниципаль милек булып торган һәм мондый оешмаларның, шул исәптән яңа төзелә торган, мөлкәт комплексларына керә торган балалар өчен социаль инфраструктура объектларының билгеләнешен үзгәртмичә, Федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, рөхсәт ителә.

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы тарафыннан балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмасын яисә муниципаль оешманы бетерү турында карар кабул итү мондый оешманың мөлкәт комплексында Татарстан Республикасы дәүләт милке яисә муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектлары булмаган очракта йә әлеге өлешнең икенче абзацы нигезендә мондый оешманың мөлкәт комплексына керә торган балалар өчен социаль инфраструктура объектларының билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү очрагында рөхсәт ителә.

Әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән карарны кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрүнең гомуми принциплары, әлеге бәяләүнең критерийларын да кертеп, шулай ук мондый карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясен булдыруның һәм аның эшчәнлегенең гомуми принциплары Федераль законның 13 статьясындагы 2 пунктының бишенче абзацы нигезендә билгеләнә.

Татарстан Республикасының дәүләт милке яисә муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү турында йә балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын яисә муниципаль оешмаларны үзгәртеп төзү яисә бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү тәртибе, мондый карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясен төзү һәм әлеге комиссия тарафыннан бәяләмәләр әзерләү тәртибе, әлеге өлешнең бишенче абзацы нигезендә билгеләнгән гомуми принципларны исәпкә алып, тиешенчә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.»;

б) 3 өлештә:

беренче абзацта «Татарстан Республикасының дәүләт милке» сүзләреннән соң «яисә муниципаль милек» сүзләрен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Балаларның ялын оештыру һәм аларны савыктыру өчен билгеләнгән объектларны урнаштыру өчен бирелгән җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнешен һәм (яисә) алардан рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү, Федераль законның 13 статьясындагы 2 пункты нигезендә дәүләт милке яисә муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектының билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү рөхсәт ителә торган очраклардан һәм мондый җир кишәрлекләрен дәүләт ихтыяҗлары яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алу очракларыннан тыш, тыела.»;

икенче абзацта түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Муниципаль милек булып торган һәм балаларга белем бирү, аларны үстерү, аларның ялы һәм аларны савыктыру, балаларга медицина ярдәме күрсәтү һәм алардагы авыруларны профилактикалау, балаларны социаль яклау һәм аларга социаль хезмәт күрсәтү максатлары өчен билгеләнгән мөлкәт муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә кулланыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 06 апрель
№ 32-ТРЗ